Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№16 (67)

16 май 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

**14 МАЙ** көнне **КФУ**ның чираттагы **РЕКТОРАТ** утырышы **УЗДЫ**. Беренче булып Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.Хашов** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше белән таныштырды. 2013 елга кабул итү кампаниясе нәтиҗәләре турында Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.Ионенко** сөйләде. Ул КФУның БДИ буенча Федераль мәгълүмати системага кушылуы турында әйтте. Профориентацион эш нәтиҗәләре белән таныштырды. Университетның РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт ярдәмен күрсәтү буенча конкурсында катнашуга әзерлеге турындагы мәгълүматны Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.Сафиуллин** җиткерде. Утырышта шулай ук Икътисад һәм финанс институтында Вроцлав Икътисад университеты һәм Санкт-Петербург Дәүләт икътисад университеты белән берлектә «Банклар һәм реаль икътисад» дигән халыкара магистр программасын ачу мәсьәләсе каралды. Финанс эшләре буенча проректор **Р.Муллакаева** профессор-укытучылар составының уртача хезмәт хакы турында мәгълүмат бирде. Филиалларны кертмичә караганда, 2013 елның I кварталына бу сумма 33 049,0 сумны тәшкил иткән. Ахырдан **А.Хашов** вуз хезмәткәрләренең пропуск режимын бозу очраклары күбәюен әйтте һәм коллегаларыннан эчке тәртип кагыйдәләренә буйсынырга өндәде.

• • • •

**КФУ** яңа форматтагы **ХӘРБИ КАФЕДРА** оештыру буенча **ЭКСПЕРИМЕНТТА** катнашачак. Бу хакта ректор **И.Гафуров** оборона промышленносте оешмалары җитәкчеләре һәм РФ югары уку йортлары ректорлары катнашында узган интернет конференциядә җиткерде. Атна дәвамында Казан федераль университетында бу мәсьәлә буенча фикер алышу алып барылачак.

• • • •

**14 МАЙ** көнне **КФУ**га **КЫТАЙНЫҢ ЭКСПОРТ-ИМПОРТ БАНКЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ** килде. Алар тышкы элемтәләр буенча проректор, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты директоры **Л.Латыйпов** белән очрашты. Визитның максаты булып үзара хезмәттәшлек итү, Кытайның эре предприятиеләрен Татарстан базарларына кертү мәсьәләләрен карау тора.

• • • •

Шул ук көнне төрек провинциясе Бурсадан губернатор **ХАРЛУТ ШАХАБЕТТИН** җитәкчелегендә **ДЕЛЕГАЦИЯ КИЛДЕ**. Кунаклар тарих музее, уку йортының хәзерге эшчәнлеге белән танышты. Үзара хезмәттәшлеккә килгәндә исә, ике як өчен дә студентлар алмашу, уртак фәнни тикшеренүләр файдалы булачак.

• • • •

ФСИ сәнгать бүлегенең «TatarStyle» костюм студиясе вузара яшь дизайнерлар һәм стилистлар конкурсында катнашты. «Студентлар подиумы-2013 «Яңа караш» конкурсы Екатеринбургның Президент академиясе Урал институтында узды. **«МИЛЛИ КОСТЮМ»** номинациясендә **«TATARSTYLE» СТУДИЯСЕ I УРЫНГА**, **«ТИЗ МОДА»** номинациясендә **ЗАЛИЯ ГАЙФЕТДИНОВАНЫҢ** иҗат эшләре **III УРЫНГА** лаек булды.

• • • •

Кытайның Фәннәр Академиясе президенты профессор **БАЙ ЧУНЛИ** танылган астрофизик, КФУның Мактаулы прфессоры **РӘШИД СЮНЯЕВНЕ ЭЙНШТЕЙН ПРОФЕССОРЫ** исеменә **ЛАЕК БУЛУЫ** белән **КОТЛАДЫ**. Мондый югары дәрәҗәгә тагын фәннең төрле өлкәләрендә уңышка ирешкән 19 чит ил галиме ия булды. Р.Сюняев Кытайның ФАсендә берничә лекция укыячак.

• • • •

КФУ ике зур проект: **АВТОМОБИЛЬ ИНЖИНИРИНГЫНЫҢ ЮГАРЫ МӘКТӘБЕН** һәм **ФУНДАМЕНТАЛЬ МЕДИЦИНА** һәм **БИОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫН** тормышка ашырырга әзерләнә. Быелгы уку елына медицина белгечлекләренә 100ләп укучы кабул ителер дип көтелә. Бу хакта КФУ ректоры И.Гафуров, Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин «БИЗНЕС Online» электрон газетасына биргән әңгәмәсендә хәбәр итте. Тулырак мәгълүматны «Казанский Университет» газетасыннан укып белә аласыз.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Вазифалар арта

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

15 май көнне ТР Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышы булды. Анда КФУ ректоры Илшат Гафуров та катнашты.

Чарада шулай ук ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, министрлык һәм башка дәүләт оешмалары, Татарстанның фәнни учреждение җитәкчеләре бар иде.

Утырышны ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мәзгәров ТР Дәүләт киңәшчесе, беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевне «Фәндәге казанышлары өчен» медале белән бүләкләүдән башлап җибәрде. «Безнең академияне булдыруда һәм үстерүдә, республиканың фәнни потенциалын саклауда катнашкан бу шәхеснең роле әйтеп бетергесез. Бүгенге көндә дә ул әлеге курсны дәвам итә, киң масштаблы проект алып бара: ике тарихи һәйкәл – Свияжск православие утравы һәм ислам кабул ителгән җир – Болгарны яңадан торгызу эшләре алып бара», – диде Ә.Мәзгәров. М.Шәймиев исә: «Мин үземне галим дип санамыйм, әмма академиянең президиум карары белән исәпләшми кала алмыйм», – дип җавап кайтарды.

Алга таба Ә.Мәзгәров «ТР Фәннәр академиясе эшчәнлегенең 2012 елдагы төп нәтиҗәләре һәм киләчәктәге планнар» исемле доклад белән чыгыш ясады. ТР Дәүләт Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшин быелгы җиңүчеләргә республика яшьләр премияләрен һәм грантлар тапшырды. Мондый күңелле атмосфера дәвам ителеп, ТР Фәннәр академиясе булдырган исемле премияләр дә бирелде. Исемлектә КФУ студентлары да бар: Максим Балакирев (Икътисад һәм финанс институты), Ольга Медведева (А.М.Бутлеров ис. Химия институты), Мария Сапаркина (Экология һәм география институты), Тимур Сафин (Физика институты), Зөһрә Шакирова (Филология һәм сәнгать институты). Профессор Ш.Т.Хәбибуллин исемендәге премиягә Физика институты студенты Клышева Элина, Икътисад һәм финанс институты магистры Нугаев Фатыйх лаек булдылар.

Тәнәфестән соң, ТР Фәннәр академиясенә яңа әгъзалар сайлау булды. Барлыгы тугыз вакансия игълан ителгән һәм академиягә әгъза-корреспондент кандидатлары арасында КФУ ректоры Илшат Гафуров («Икътисад, халык хуҗалыгын оештыру һәм аның белән идарә итү (төбәкләрнең иҗтимагый-икътисади үсеш стратегияләре)» белгечлеге буенча) та бар иде. Сайлаулар яшерен тавыш бирү формасында үтте. Сайлауда катнашучыларның 73% И.Гафуров өчен тавыш бирде һәм, шул рәвешле, КФУ ректоры ТР Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты исеменә лаек булды.

## • Бездә кунак бар

# Экосистемалар сагында

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Кичә Халыкара табигатьне саклау союзы комиссиясе рәисе Пит Уит (фотода сулда) һәм Эстон социаль фәннәр һәм табигать-мәдәни ландшафт һәм табигый мирасны саклау һәм идарә университеты профессоры Калева Сеппа (фотода уңда) КФУ укытучылары һәм студентларына «Экосистемалар үсеше. Хәзерге заман тәҗрибәсе» дигән темага лекция укыды.

Татарстанда экология культурасы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы кысаларында «Бердәм экология дәресе» дип исемләнгән экология-мәгърифәти акция уздырылды. КФУда әлеге дәресне чит ил галимнәре үткәрде. Халыкара табигатьне саклау союзы – коммерциягә корылмаган халыкара оешма. Ул планетабызның биотөрлелеген саклау мәсьәләсен яктырту белән шөгыльләнә. Әлеге оешма вәкиле Калева Сеппа үз чыгышында бүген Җир шарының кризис хәлендә булуы, климатның үзгәрүе аркасында катастрофаларның артуы хакында сөйләде. Моның төп сәбәбе: табигатькә зыян сала торган яңа технологияләр, яшел булмаган икътисад һ.б. Галим катнашучыларны IUCN 2013-2016 программасы белән таныштырды. Пит Уит исә Халыкара табигатьне саклау союзыныңниләр белән шөгыльләнүе, төп максат-бурычлары хакында сөйләде.



Диана Поварова фотосы

• Галимнәребез

# Халкына багышланган гомер

ТЕЛНЕ, ҮЗ ХАЛКЫН ЯРАТУЫ, ХЕЗМӘТ СӨЮЕ, ТАШЫП ТОРГАН ЭНЕРГИЯСЕ ҺӘМ ТҮЗЕМЛЕГЕ АНА БАРЛЫК КЫЕНЛЫКЛАРНЫ ҖИҢӘРГӘ, ҮЗ ЮЛЫННАН ТАЙПЫЛМЫЙЧА АЛГА БАРЫРГА, МАКСАТЫНА ИРЕШЕРГӘ ЯРДӘМ ИТӘ. УЛ СОҢГЫ СУЛЫШЫНА КАДӘР ХАЛКЫБЫЗНЫ ЯКТЫЛЫККА ИЛТҮ ЮЛЫНДА АРМЫЙ-ТАЛМЫЙ ХЕЗМӘТ ИТКӘН ШӘХЕС.



✦ **Мөхетдин Корбангалиевнең** нәсел дәвамчылары да хезмәт юлларын фән белән бәйләгән. Аның улы – Салих Корбангалиев – танылган хирург, медицина фәннәре кандидаты, профессор Казан университетын тәмамлый. Медицина институтына нигез салучыларның берсе һәм ректоры, 1932 елдан башлап, сәламәтлекне саклауның халык комиссары булып тора. Кызы Хәлимә Корбангалиева – шулай ук Казан университеты профессоры. 1950-1974 елларда зоология һәм умырткалылар кафедрасын җитәкли.

Татар халкының күренекле галиме, мәгърифәтче, танылган педагог һәм методист, атказанган фән эшлеклесе, хезмәт каһарманы, орденлы профессор Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев 1873 елның декабрендә элекке Вятка губернасы, Алабуга өязе, Сарсак-Умга волостеның Биектау авылында (хәз. Әгерҗе районы Биектау авылы) ярлы крестьян гаиләсендә туа.

Булачак галим кечкенәдән үк укырга һәм белем алырга омтыла. Үзенең яшь вакытында укырга, белем алырга булган теләген тормышка ашыра алмаган Хафиз ага улы Мөхетдинне укытып мулла итәргә уйлый. Ләкин аның «учитель» булырга дәрте барын күргәч, теләгенә каршы килмичә, үз ихтыярына куя. Авылларындагы русско-татарская школаны тәмамлагач, Мөхетдин «Казанская татарская учительская школа»га укырга китә. Ләкин аны школадагы дәресләр генә канәгатьләндерми, ул, рус теле белән беррәттән, татар телен дә өйрәнә, күренекле кешеләр, шул исәптән К.Насыйри белән таныша, аннан киңәшләр ала. М.Корбангалиев бер язмасында халык әдәбиятын җыюга карата К.Насыйриның үзенә юл күрсәтүен әйтә: «...Бу юлы авыл мәктәбендә җыйган җырларымны, бәетләрне алып барган идем. Ул аларны өстән-өстән карады да, картлардан сөйләтеп җыярга кушты... Мин җәй көне, авылга кайткач, шул күрсәткән юл белән байтак нәрсәләр җыйдым», – ди.

1895 елда Казан шәһәрендәге Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Авыл мәктәпләрендә укыта. 1903 елда Казандагы балалар йортына мөдир итеп билгеләнә. Шушы елларда башлангыч һәм олылар мәктәбе өчен татар әлифбалары төзи, татар теле, математика һәм география буенча дәреслекләр чыгара. «Мәктәп» һәм «Мәгариф» журналлары белән хезмәттәшлек итә.

1928 елда совет хокукы факультетына лектор итеп куела. 1928-1929 елларда, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире буларак, барлык факультетларда, татар телен укыту мәсьәләсен күтәрә. «...Университетта укучы татар һәм татар булмаган студентларга, каян чыгышларына карамастан, татар телен өйрәнүне мәҗбүри куярга, татар телен белү Татарстан республикасындагына түгел, ә татар-төрек халыклары булган башка республикаларда да эшләргә мөмкинлек тудырачак...» – дип, университет ректорына яза. 1931–1932 уку елында М.Корбангалиевкә университетта үтелә торган барлык фәннәр буенча татар телендә гыйльми терминнарны эшләү өчен терминология комиссиясе төзү һәм аның белән җитәкчелек итү эше тапшырыла. Аның җитәкчелегендә бу комиссия тарафыннан бер ел эчендә 17500 гыйльми термин теркәлә.

Мөхетдин Корбангалиев мәгариф өлкәсендә татар халкы өчен күп эш башкара, туган телдә укыту балаларга белем бирүдә һәм аларны тәрбияләүдә яхшы чыганак дип саный. Мөхетдин Корбангалиев татар теле орфографиясен камилләштерү буенча да күп хезмәт куя. 1939 елда, Шиһаб Рамазанов белән бергә, татар алфавитын рус графикасына күчерүне тәртипкә сала. Күп еллар дәвамында Татар педагогик җәмгыятен оештыручы һәм аның даими рәисе була. Корбангалиевның мирасы гаять зур һәм күпкырлы. Галим үзе күрсәткәнчә, ул 96 китап язган. Архив документларында аның 130 фәнни хезмәте бар, диелә.

Шуның өчендә Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиевне халкыбыз дан-хөрмәт казанган галимнәрнең берсе дип таный һәм онытмый. Галим 1941 елның 3 июнендә Казанда вафат була. Казанның Татар зиратында җирләнә.

• Чара

# Толерантлыкка бер адым

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

13 МАЙ КӨННЕ КФУНЫҢ КӨНЧЫГЫШНЫ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ ХАЛЫКАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫНЫҢ АКТЛАР ЗАЛЫНДА «ЯКЫН КӨНЧЫГЫШ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ПРАКТИК КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ.



▪ Сулдан уңга: *Л.Латыйпов һәм Ш.Воскобойник.* Диана Поварова фотосы.

Чараны Казан федераль университеты, **Израиль дәүләтенең РФдәге илчелеге һәм «Чиксез изгелек»** («Добро без границ») халыкара оешмасы үткәрде.

Тышкы элемтәләр буенча проректор **Линар Латыйпов** катнашучыларга Казанның көнчыгышны өйрәнү мәктәбе тарихы, Казан университетында әлеге юнәлеш буенча күптән түгел генә уздырылган реформалар хакында сөйләде. Израиль дәүләтенең РФдәге илчелегенең беренче сәркатибе **Шломо Воскобойник** үз чиратында милләтара һәм дини толерантлыкка багышланган лекция укыды.

Үз чыгышын лектор Тора, ягъни яһүдиләрнең традицион канунына нигезләде. «Без төрле, ләкин ничек тә булса аралашырга тиеш. Үзебезгә охшамаган кемгә дә яки нәрсәгә дә булса мөнәсәбәт белдерергә туры килгәндә, билгеле бер чикне узабыз. Шуның өчен бөтен кеше белән дә уртак тел табып, шул ук вакытта үз «мин»еңне югалтмыйча яши белү мөһим», – дип белдерде Шломо Воскобойник. Ул үзенең фәлсәфи фикерләрендә Израильнең сәяси тормышына да кагылып үтте.

Израильне икътисади яктан алга киткән, дини хорафатларга бирешми торган ил буларак сурәтләп, лектор яһүдиләрнең гореф-гадәтләрне аеруча хөрмәт итүләрен билгеләп үтте. Израиль төрле илләрдән күчеп килгән кешеләргә бай, шуңа биредә милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсе бик мөһим. Гарәп һәм яһүд халкының бер-берсенә тәэсире урыс һәм татар халкы арасындагы мөнәсәбәтләргә охшаш.

Гарәп һәм яһүдиләр уртак тамырларга ия булса да, Израильдәге катнаш никахларга карата булган тискәре мөнәсәбәт әлеге ике милләт арасында үзара каршылыкка китерә икән. «За всеобщий мир» федерациясе президенты Дмитрий Самко Татарстанның милләтара мөнәсәбәтләрне җайлау буенча тәҗрибәсе Израиль өчен дә файдалы булырга мөмкин дигән фикер җиткерде.

Чара кысаларында «түгәрәк өстәл» оештырылды. Катнашучылар «Толерантлык – милләтара хезмәттәшлекне үстерү факторы» һәм «Толерантлык – Якын Көнчыгыш мәсьәләсен җайга салу факторы» дигән темага фикер алышты.

• Аталар сүзе - акылның үзе

ОКТЯБРЬ ИНКЫЙЛАБЫНА КАДӘР РОССИЯДӘ ЯШӘҮЧЕ ҺӘР ХАЛЫКТА ӨЧ ТӨРЛЕ КАЛЕНДАРЬ КУЛЛАНЫЛЫШТА БУЛГАН: РӘСМИ-ГРАЖДАНЛЫК, ДИНИ ҺӘМ ГРАЖДАНЛЫК КАЛЕНДАРЕ. АЛАР КҮПЧЕЛЕК ОЧРАКТА ҮЗАРА ТӘҢГӘЛ КИЛМӘГӘННӘР. ЧӨНКИ ПАСХА ЯКИ РАШТУА, УРАЗА ЯКИ КОРБАН БӘЙРӘМНӘРЕ, БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ ТОРГАН РӘСМИ ДАТАЛАР, ШУЛАЙ УК ХАЛЫК КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА КИЛӘ ТОРГАН ЙОЛА-БӘЙРӘМНӘР – ӨЧЕСЕ ӨЧ ХАРАКТЕРДА БУЛГАН.

# Беренче буразна бәйрәме

**Регина РАЯНОВА,**
татар филологиясе бүлеге

Татар халык календаре, башка халыклардагы кебек үк, ел фасылларына һәм хуҗалык эшләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Икенче төрле әйткәндә, халык календарендагы төрле даталар, йола-бәйрәмнәр крестьяннарның ел да бер тәртиптә кабатлана торган хезмәтенә, теге яки бу авыл хуҗалыгы эшенең кайчан, ничек каршылануына һәм башкарылуына нигезләнеп формалашкан. Халык календареның аграр характерда булуы, билгеле, бик табигый. Борынгы заманнан ук инде игенче-крестьян тормышы җиргә, табигатькә бәреккән булган. Һәм аңа ул үзенчә яраклашырга, хуҗалык эшләрен дә табигать һәм ел фасыллары үзгәрешләренә туры китереп алып барырга тырышкан. Җир эшләренә бәйле рәвештә, ул магик характердагы төрле йолалар һәм шулар башкарылганда әйтелә торган төрле сүзгыйбарәләр уйлап чыгарган.

Гасырлар дәвамында барлыкка килгән йола иҗатының төп өлешен җир эшкәртү, иген үстерү, уңыш алу, мал асрауга бәйле йолалар һәм текстлар алып тора. Ел фасылларына бәйле рәвештә, әлеге синкретик фольклор дүрт өлешкә бүленеп йөртелә: кышкы, язгы, җәйге, көзге.

Ә менә бездә, ягъни Башкортстанның Дүртөйле районы Түбән Аташ авылында үткәрелә торган Беренче буразна бәйрәме югарыда сөйләп узганнарның ачык мисалы булып тора.

Беренче буразна (беренче сабан) бәйрәме безнең якларда бик зурлап үткәрелә. Беренче буразна – ул беренче чәчүгә төшкән көн. Бу бәйрәмне, гадәттә, мәктәп укучылары белән берлектә, мәдәният йорты хезмәткәрләре әзерли. Мулла бабай, берничә әби, күп кенә колхозчылар басуга килә. Башта, игенчеләргә дан җырлап, укучылар концерт куя. Әлбәттә, монда игенче һөнәренә багышланган күп шигырьләр сөйләнә, җырлар җырлана, мәкаль-әйтемнәр яңгырый.

*Рәхмәтебез нинди зур сиңа,*
*Илгә бәхет иҗат итүче.*
*Урал батыр сыман*
*мәңгелек син,*
*Иген кырларында игенче.*
*Яланнарда сезнең алтын*
*куллар*
*Алтын бөртек бит ул*
*үстерә.*
*Сезнең икмәк күпме гаиләгә*
*Кыш чыкканчы кояш китерә.*

Концерттан соң, колхоз рәисе, агроном, бригадир һәм башкалар чыгыш ясап, үз теләкләрен җиткерәләр.

*Икмәк көче, икмәк көче,*
*Дан, хөрмәт сиңа, ИГЕНЧЕ!*

Ак юл сезгә, хәерле сәгатьтә! – дип, иң алдынгы механизаторларга чигүле ап-ак тастымалга куелган ипи-тоз бирелә. «Чәчүләр уңышлы үтеп, игеннәр күкрәп үссен. Сезнең эшләр һәрчак алда барсын. Без сезнең хезмәтегезне зурлап баш иябез. Һәр ел язы безгә зур уңышлар алып килсен. Әссәламегаләйкем! Бисмилләһир-рахман ир-рахим!» – дип, дога укыла.

Шуннан соң иң кызыгы башлана: игеннәр йомырка кебек тәгәрәшеп үссеннәр дип, буразнага төрле төскә буялган йомыркалар чәчәләр. Бала-чагалар йөгерә-йөгерә җыялар. Бу вакытта инде тракторлар басу кырыена тезеп куелган була һәм беренче буразнага орлык чәчелә башлый.



• Хатирә

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә» истәлекләр циклы.

# «Казан. Университет»

*«Монда, бу бинага атлап кергән яшьләр бер фикере дә булмаган буш сүзләр ишетмәсләр».*
(Н.И.Лобачевскийның 1828 елда Казан университетында сөйләгән реченнән.)



▪ *Аспирантурага кергәндә соңгы имтиханнан соң. Казан, 11 сентябрь, 1960 ел*

Университет... Монда кереп уку минем мәңгелек хыялым иде. Ләкин керә алмаячагымны да белә идем. 1947 елның июлендә аттестатымны гәзиткә төреп тотып шул бинаның колонналары янында басып тордым. Күзгә яшь бөялде. Чалгыдан, сәнәктән, «уфалла» арбасыннан кичә генә аерылган яшүсмер ничек итеп шундый мәшһүр уку йортына укырга керә алсын инде? Һәм мин авыл халкы өчен бераз якынрак булган Болак буе педагогия институтына киттем. Анда керә алдым тагы...

Ә теге хыял мине эзәрлекләде. Шул хыял миңа тынгылык бирмәде. Университет значогы таккан яшьләрдән гомер буе көнләштем.

Һәм 1960 елның сентябрендә имтихан биреп татар әдәбияты кафедрасына аспирантурага кердем. Керүем бик кызык булды: немец теленнән имтихан биргәндә әзерлегем бик түбән икәнлеге беленгәч, имтихан алучы Евдокия Алексеевна Кирпичникова чәчәнә ябышты:

– Сез нәрсә уйлыйсыз, ничек кандидатский минимумны бирерсез? – диде. Мин батырлыгымны җыеп:

– Әгәр миңа уңай билге куеп чыгарсагыз, ант итәм: минимумны мин яхшы билгесенә тапшырачакмын. Ант итәм. Антыма ышанмасагыз, хәзер үк икеле куегыз, ләкин мине газапламагыз, – дидем. Ул ыңгырашып миңа «уд» куйды. Алга таба узып шуны әйтеп куйыйм: мине икенче бер юньле хатын Марианна Николаевна Пахомова укытты һәм зур дәүләт комиссиясе алдында кандидатлык минимумыннан чак-чак кына бишле алмадым. Комиссия әгъзалары киңәшеп миңа дүртле куйганда Марианна Николаевна болай диде:

– Ах, бөтен аспирантларым да шундый үҗәт, шундый максатчан булсалар иде, бу иптәш бит нольдән башлады. Мондагы тырышлык!

Анысы бардыр, анысы сугыш вакытында ач көе тезләнеп «уфалла» арбасы тартканда ясалгандыр.

Татар әдәбиятын тапшырганда комиссиядә Х.Госман, Я.Агишев, З.Мәҗитов иде. Тегеләрен танысам да, З.Мәҗитовны белми идем: бу нинди малай-шалай миңа сорау биреп бәйләнеп утыра соң, дип ачудан тешләремне кысып җавап бирдем. Зәет шундый яшь иде әле!

Ахырдан сөйләде: мине чыгарып җибәргәч, билге турында киңәшкәндә Якуп ага әйткән:

– Хатыйп, бу егеттә өмет бар бит, бишле куйыйк, – дигән. Шулай бишле куйганнар. КПСС тарихын биргәндә ниндидер төгәл булмаган фраза ычкындырып харап була яздым: имтихан алучы Р.И.Нафигов нәгърәләрен орды инде, сүкте, дулады. Гадәтенчә, сүтелеп бетте. Югары белемем буенча тарихчы икәнемне белгәч, үз итеп, «коллега» итеп, ихтирам белән сүкте. Аннан елмаеп кулны кысты. Бераздан мине аспирантурага алу турында приказ чыкты.

*(Дәвамы киләсе саннарда)*

• Тукай оныклары

Быел Габдулла Тукайның вафатына 100 ел тулды, шул уңайдан «Тукай 100е» дигән мәдәни чара узды.

# Тукай 100е!

**Эльвина НӘҖИПОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

*Бер заман бардым Печән базарына, –*
*Шунда мин таптым азык язарыма.*



*Быел татар җәмәгатьчелеге Габдулла Тукай үлеменә 100 ел тулуны билгеләп үтә. 1913 елның 15 апрелендә (яңа стиль буенча) 20 сәгать 15 минутта бөек татар шагыйре Габдулла Тукай вафат була. Шагыйрь нибары 27 яшьтә бакыйлыкка күчә.*

Бу юллар Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасыннан. Элек Печән базары урнашкан җирдә Бөтендөнья татар яшьләре форумының Казан шәһәре активы Казаныбызга Тукайны яңача тәкъдим итте.

Париж коммунасы урамында «Печән базары ярминкәсе» дип аталган театральләштерелгән тамашада XX гасыр башы рухында киенгән яшьләр төрле кул эшләрен һәм милли ризыклар сатуны, татар шигъриятенең яңа буыны тарафыннан куелган «Шигърият сәгате»н күзәтергә мөмкин иде. Чараны Раил Өметбаев алып барды.

Чарада «Аң» журналын таратырлар. Бу санда Габдулла Тукайның үлеме турында язма, Печән базарының тарихы һәм рус телендә Тукай турындагы кызыклы мәгълүматлар урын алган иде. Ярминкә барышында яшьләр, студентлар һәм мәктәп укучылары ярдәмендә XX гасыр башы мохите тудырылды. Габдулла Тукай нәкъ шул чорда яшәгән һәм иҗат иткән. Казан халкы үз күзләре белән шул дәвердәге тиралек бизәлешен, киемнәр стилен карый алды, шул чорга әйләнеп кайткан кебек булды.

Ярминкәдә, урта һәм югары уку йортлары шәкертләренең кул эшләнмәләре белән бергә, зәркәнчеләр дә үз продукциясен тәкъдим итте. Татарча язулы, милли бизәкле, Казан күренешләре ясалган открыткалар, кулъяулыклар, бала киемнәре, чынаяклар бар иде. Лаештосларыагачтан эшләнгән мәчет пазллары, каеп ясалган тартмалар сатты. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе кызлары үзләре пешергән кабартма, өчпочмак, кыстыбый, баллы ризыкларын тәкъдим итте. Шунда ук теләгәннәр самовардан чәй эчә алды. Ярминкәдә катнашучыларны яшь шагыйрьләр: Йолдыз Миннуллина, Рүзәл Мөхәммәтшин, Фәнил Гыйләҗев, Булат Ибраһим һ.б. үзләренең милләт турындагы шигырьләрен укыды. «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» шәкертләре бәйрәм кунакларын шаян мәзәкләре белән «сыйлады». Ахырдан бөтен кеше Тукай рухына дога кылды һәм чара «Туган тел» җыры белән тәмамланды.

*P.S. Шундый зур чараны оештыруда, үткәрүдә катнашкан һәр кешегә рәхмәт. Ләкин юллар ябык булмау сәбәпле, ярминкәдә катнашучыларга юлның бер ягыннан икенче ягына чыгып йөрү кыенлык тудырды. Алдагы елларда мондый зур масштаблы чараларга ЮХИДИ хезмәткәрләре дә битараф калмас дип уйлыйбыз.*

• Абитуриент колагына

# Дипломның да була төрлесе

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Белем системасы көннән-көн үзгәрә. Бөтен мәктәп укучыларын куркытып бетергән БДИга әле ияләшеп бетәргә өлгермәдек, тагын бер яңалык керттеләр. Югары уку йортлары тулысы белән ике баскычлы белем бирү системасына – бакалавриат һәм магистратурага күчә.




**✦Лилия Гәрәева,**
хезмәткәрләр табып бирү компаниясе җитәкчесе:

– Бакалавриатны тәмамлаган кешеләр эшкә урнаша алалармы, дигән сорауга конкрет җавап биреп булмый. Чөнки бу очракта күп нәрсә ул укыган белгечлектән тора. Мәсәлән, икътисад һәм юридик юнәлешләр буенча укыган бакалаврларга эш табу бик кыен булачак. Чөнки әлеге тармакларда эшләү өчен тулы белем алган, ягъни магистратураны тәмамлаган кешеләр кирәк. Ә менә заводларга яки предприятиеләргә урнашырга теләгән бакалаврларны дүрт куллап эшкә алалар. Аннары аларны үстереп, киләчәктә магистратурада укып чыгарга мөмкинлек бирәләр. Сәүдә тармагында да бакалавриатка яхшы белгеч буларак карыйлар. Әлеге диплом белән килгәннәрне эшкә алып, аларга төрле тренинглар уздыралар. Нәтиҗәдә, үзләренә кирәк булган белгечләрне әзерлиләр.

## Аңламыйча бардык

Без, укырга кергән вакытта, зур сынау алдында калдык – бакалавриатны сайларгамы, белгечлекнеме? Нәрсәнең нәрсә икәнен дә төгәл белми идек. «Бакалавр» әллә нинди ят сүз булып тоелгангадырмы, күбебез һәркемгә таныш булган «белгеч» статусын алып чыгарга карар кылды. Чынлап та, кем соң ул бакалавр, кем ул магистр? Европадагы белем бирү системасы безгә ник кирәк булды икән?

Уйлап карагыз әле, ни өчен Россиядә алган диплом белән чит илдә эшкә урнашып булмый? Төп сәбәп квалификацияләр бүленешендә. Мәсәлән, Россиядә «инженер», «тарих укытучысы», «журналист» белгечлек булып санала. Ә чит илдә болар бары тик хезмәт урыны гына, ягъни вазифа. Икенчедән, чит илләрдә мәктәптә 14 елга якын белем алалар. Шуңа күрә вуз студентлары дүрт еллык бакалавриат курсын тәмамлап, югары белем дипломнары белән чыга. Ә иң талантлылар, укуларын дәвам итеп, магистратурага бара.

Мондый система бездә дә тамыр җәеп китә алса, Россиядә алган дипломнар белән чит илләрдә дә эшкә урнашып булачак.

## Диплом бар, эш юк

Танышларым арасында да бакалавриатны тәмамлаганнар бар. Тик әлеге диплом белән эшкә урнаша алганнары гына аз. Лилия, мәсәлән, былтыр гына диплом алды. Укырга кергән елны, югары белемле дүрт ел эчендә алып чыгам да эшкә урнашам, дигән уй белән белгечлекне түгел, ә бакалавриатны сайлаган иде. Хәзер менә эшкә урнаша алмыйча йөри.

Дипломын тотып кая гына барса да: «Бакалавр? Ә кем ул? Безгә югары белемле белгечләр кирәк», – дигән җаваплар ишетте. Бакалаврның да югары белем иясе икәнлеген күпме генә аңлатырга тырышса да, эш бирүчеләрне ул канәгатьләндермәде.

Рамил исә югары уку йортына белем алу өчен түгел, ә диплом алу өчен генә керде. Ул армиягә бармаска һәм кулына бирәр «катыргы» алып чыгарга теләде. Дүрт еллык бакалавриатны сайлавы да шуңа бәйле иде. Хәзер бер дә үкенми. Рәхәт студент тормышын да татыды, диплом да алды. Эшкә урнашу белән дә мәшәкате булмады. Җитәкче аның дипломы булу-булмавы белән генә кызыксынган. Бакалавриат сүзен ишеткәч, бераз каушап калса да, соңрак кулын селтәп: «Әй, тагын берәр нинди яңалык уйлап чыгарганнардыр инде. Эшли алсаң, теләсә нинди дипломың булсын», – дип кенә җибәргән.

## Асылы нидә?

Бакалавр ул – шундый ук югары белемле белгеч, тик аны бөтен җиргә дә эшкә алмаска мөмкиннәр. Кайбер чикләүләрне алып ташлар өчен аңа тагын ике ел магистратурада укырга кирәк.

Болонья системасы дип аталучы әлеге белем бирү системасының асылын медицина вузлары мисалында аңларга була. Мәсәлән, дүрт ел укыган студент гомуми профильле табиб булып чыга. Ә менә кардиолог булыр өчен аңа тагын ике ел укырга кирәк.

Бакалавриат АКШ та бик популяр. Анда яшьүчеләрнең күбесе магистратурада укымыйча, бакалавр дипломын гына алып чыга.

● Әдәби сәйләннәр

# Яшьлек хатасы



Раил Садретдинов – әдәбиятка шагыйрьләр Миргазиз Укмасый һәм Кадыйр Сибгатуллинны бүләк иткән Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылыннан. Туган авылының данлыклы шәхесләре, тарихы, табигате белән кызыксына. Бу өлкәгә бәйле фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгыш ясап, призлы урыннар яулаганы бар. Хәзерге көндә Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының татар журналистикасы бүлегендә беренче курста укый.

Кая барырга? Нишләргә?..Гөлгенәнең уенда кичә генә бу сораулар юк иде. Бу көнгә кадәр ул кайгы белмичә, бөтен шартлары, саунасы, бассейны булган йортта рәхәт тормыш кичерде. Шул рәхәтлек бер мизгел эчендә юкка чыгар, дип кем уйлаган? Ә бит барысы да бик яхшы башланган иде...

Гөлгенә әти-әнисен хәтерләми дә... Кыз бик кечкенә вакытта, алар бер-бер артлы бакыйлыкка күчкәннәр. Тик шулай да әтисен аз-маз күз алдына китерә әле. Аның хәтерендә ул кара чәчле, кыска мыеклы, зур йодрыклы баһадир ир-ат буларак кереп калган.

Әнисе, мәрхүм, үзе дә ятимә булган шул. Ни әти-әнисе, ни апа-абыйсы булмаган аның. Шуңа да Гөлгенә әтисе ягыннан булган әбисе һәм бабасы янында үсә. Тәрбияне дә, әдәп-әхлакны да аз бирмиләр аңа. Тик шулай да, Гөлгенә кечкенәдән үк әти-әнисе югын, яклаучысыз калганын аңлап яши. Үсәтөшкәч, әби-бабайның да мәңге яшәмәячәгенә төшенә. Шуңа ул ни эшләсә дә, аңа бары үзенә генә җавап бирергә кирәк буласын белә. Һәр сүзен үлчәп сөйли, хисләрен үз кулында тота белә торган кыз булып үсеп җитә. Башкалардан бер дә ким укымый. Укытучылар да, мәктәп коллективы да кыз баланың психологиясенә зыян китермәскә тырыша.

Мәктәп еллары шаулап узып китә. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган Гөлгенә, шәһәргә китеп, белем алырга карар кыла. Әби-бабасы иркәләп үстергән гөлләрен бер дә җибәрергә теләми. Телевизордан, радиодан һаман илгә белемле, укымышлы «кампитрлар» белән эшли ала торган «кадрлар» кирәк дип тукып торалар. Гөлгенәгә дә бөтен «сүз байлыгын», үҗәтлеген эшкә җигәргә туры килә. Әби-бабасын юмалап, бераз хәйлә дә кулланып, үз дигәненә ирешә.

Гөлгенә, шәһәргә килгәч, үзен ирекле коштай сизә. Кая теләсә, шунда бара. Театр-музейларны, концерт-кәмитләрне «гизә». Дөрес, үзенең төп максатын – яхшы итеп укуны да онытмый. Озак дип тоелган студент еллары да үтеп китә. Эх, чыннан да ничек күңелле иде алар!

...Гөлгенә бүген никтер үткәнендә казына, хәтерендә иң мөһим вакыйгаларын барлый. Кайгы-хәсрәт, күңелсезлек килгәндә, ул шул бәхетле минутларыннан көч-дәрт алып яши. Гомернең бәхетле мизгелләре – күңелнең «заряд аккумуляторы» ул.

Гөлгенә артыннан егетләрнең ниндиләре генә йөрмәде. Тик Гөлгенә аларның берсен дә янына якын җибәрмәде. Ул да, күпләр кебек, акбүз атка атланган «принц»ны



көтте. Студент елларында аның хәтеренә бер сөйләшү кереп калды. Яшь-яшь кенә студенткалар кемнең нинди егет сайлаячагы турында гәпләшәләр. Барысы да үз фикерен әйтергә ашыга. «Җирдә бер генә яшибез. Мин кияүгә бай егеткә, рәхәт тормыш күрер өчен чыгачакмын» – дип үз сүзен әйтте шулчак Гөлгенә. Арадан бер дусты: «Синең ул бер көнлек байлыгың нигә кирәк? Кияүгә мин бары йөрәгем кушуы буенча гына чыгачакмын», – дип Гөлгенәнең сүзләренә каршы чыкты.

Гөлгенәдә, ниһаять, кияү кочагына керде. Кияүнең дә ниндие әле: чит илдә вилласы, илебезнең унлап шәһәрендә үз «почмагы» – коттеджы, фатиры булганына. Гөлгенә яңа тормышның бөтен ләззәтен-тәмен тоеп яшәде. Әби-бабай дөньядан китеп баргач, авылга кайтудан да туктады. Яңа тормыш иске, сыналган дусларны да оныттырды.

Гөлгенә Русланны башта үк бик ошатты. Танышулары да кинәт кенә килеп чыкты. Гөлгенә ул көнне эштән кайтырга соң чыкты. Тукталышта алар ягына бара торган бер генә автобус та килмәгәч, узып бара торган машиналарга кул күтәрә башлады. Байтак кына вакыт торгач, аны Руслан «алып китте». Шуннан бер айлап очрашып-күрешеп йөргәннән соң, Руслан аңа тәкъдим ясады. Яшьләр, туйны артык чыгымга санап, үткәреп тормадылар. Бергә яши башлаганның икенче көнендә үк һәркем үз эше белән мәшгуль булды.

Шулай көннәр, айлар, еллар узды. Тыныч, бик матур гына башланган тормышта ниндидер кытыршылыклар сизелә башлады. Руслан җитәкләгән фирманың соңгы вакытта эшләре бик мөшкелләнде, клиентлары да кимеде. Фирманың киләчәктә банкротлыкка каласы көн кебек ачык иде. Шуңа да Руслан үз киләчәген кайгырту эшенә керешә, ә ул «яңа», «матур» киләчәктә Гөлгенәгә урын билгеләнмәгән иде. Гомумән, Руслан өчен инде ул күптәннән юк. Ул Гөлгенәгә ниндидер бер күңел ачу чарасы, курчак итеп кенә карады.

Менә ишек шакыдылар. «Әллә Русланмы?» – дигән уй үтте Гөлгенәнең башыннан. Булмас, бер киткәннәр кире кайтмый. Әйе, Гөлгенә Русланның, аны ялгызын тормыш чоңгылына ташлап, чит илгә очуын белә иде инде. Безнең илдә бит байлыкны тиз бүләләр. Фирма банкротлыкка чыккан көнне үк, суд приставлары килеп, милекне язып киттеләр, Гөлгенәгә тиз арада фатирны бушатырга дигән әмер бирделәр. Мескен Гөлгенә бары шул вакытта гына бу тормышта ничек алданганын, сандугач артыннан куып, чыпчыкны ычкындырганын аңлады.

Тагын ишек шакыйлар...

● Экология культурасы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы

# Экология гореф-гадәтләре

Педагогика фәннәре докторы, географик һәм экологик белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы профессоры Җәүдәт Хәсәеновның фәнни-гамәли хезмәтләре философия фәннәре докторы, профессор Н.М.Солодухо җитәкчелегендәге «Гомуми экология» проекты кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт премиясенә тәкдим ителде. Нәтиҗәләр ел ахырында ясалачак.

Кешелек дөньясының хәзерге үсеш этабы табигать белән җәмгыять арасындагы каршылыклардан тора һәм, шуның нигезендә, тирән социаль-экология кризисы барлыкка килде. Әйләнә-тирә мохит кискен үзгәреш кичерә: ул химик, физик элементлар белән пычрана, туфракның продуктлылыгы һәм уңдырышы нык түбәнәя, ашамлык ризыкларының сыйфаты начарая. Кешелек җәмгыяте һәм табигать арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең бозылуы бик күп сандагы үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының юкка чыгуына китерә. Нәтиҗәдә кешенең иммун системасы төшә, нәселдәнлек үзгәрә, организмның авыруларга каршы торучанлыгы кими.

Кешелекнең үз-үзен юкка чыгара баруы, җәмгыять, мәктәп һәм педагогика фәне алдына бүгенге һәм киләчәк буын укучыларында, яшьләрдә экология культурасын барлыкка китерү бурычын куйды. Без, үз чиратыбызда, борынгыдан килгән гыйлемнәргә таянабыз. Ул заманда



«экология» төшенчәсе, гомумән, булмаган. Ләкин халыкның бай тормыш тәҗрибәсенә нигезләнгән экология белемнәренә ия булуы хакында гарәп, рус һәм башка милләт вәкилләре, сәяхәтчеләре, галимнәре язып калдырган. Тарихи-этнографик материаллар нигезендә, безгә шунысы мәгълүм: татар халкы табигый мохит белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Татар халкының дәвамлы тарихы, иртә дәүләтчелек туу, аның тормышында экология культурасы югары булуы хакында сөйли.

Фольклор материаллары табигать һәм кешелек дөньясы, социаль тормышның бер-берләренә нык бәйле булуын тагын бер мәртәбә раслый. Үткән заманның педагогика һәм табигатьне саклау белемнәре, экологияне тагын да тирәнрәк аңларга һәм аны һәрьяклап өйрәнергә кирәклеген күрсәтә, нәтиҗәдә яшь буында экология культурасы формалашуга уңай йогынты ясый.

Татар халкының табигать педагогикасы һәм экология турындагы белемнәре хәзинәсен авыл җирендә яшәүче әби-бабайлар саклый. Шунысы кызганыч: әле бүген дә гомуми белем бирү мәктәпләрендә, гимназия-лицей, югары уку йортларында һәм аларның укыту программаларында халыкның экологик белемнәрен, традицияләрен өйрәнүгә әһәмият бирмиләр һәм зур хата ясыйлар.

● Студентлар рекорды

# Иң озын карандаш



● 1995 елда Нью-Йорк студенты дөньядагы иң кечкенә табиб дәрәҗәсенә ирешә, тогәлрәк, ул үз эшенең остасы, квалификациядә белгеч булып җитешә. Бу вакытта аңа унҗиде яшь була.

● 1994 елның июнь аенда Майкл Керни иң яшь чыгарылыш студенты исемен лаек була. АКШның Көньяк Алабама университетының гуманитар фәннәр буенча бакалавр дәрәҗәсен ала. Бу вакытта аңа нибары 10 яшьтә 4 ай була.

● Дөньядагы иң озын карандаш (озынлыгы 2,74 метр) Хаддерсфилд техник колледжы студентлары тарафыннан ясалган. Ул 1995 елда Бөекбританиянең «Клиф Хилл» мәктәбе кушуы буенча эшләнә.

● Американың Иллинойс штаты докторы Роланд Дант Чикагода 1986 елның 1-2 июнендә укыган ике көнлек гипнотерапия лекциясе курслары өчен, тарихтагы иң зур гонорарны (3 080 000 доллар) ала.

● 1997 елның 1-2 мартында Миссури-Ролл университетыннан 60 студент Хәйрия акциясе кысаларында 65,44 км озынлыктагы 450 000 буыннан торган иң озын кәгазь чылбыр ясый.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.